# ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында
Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Зур Ключи авыл җирлегенең Ивановское авылы торак пунктында

**21 октябрь 2023 ел** **№2/2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Зур Ключи авыл җирлегенең Ивановское авылы торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Зур Ключи авыл җирлегенең Ивановское авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I, II төркем инвалидлардан, күп балалы гаиләләрдән, Бөек Ватан сугышы инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Чернобыльдән, Бөек Ватан сугышы тол хатыннарыннан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 1600 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Су башнясын сатып алу (смета төзү һәм техник контроль);

2) Урам яктырту (материаллар сатып алу, смета төзү һәм техник контроль).

3. Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында Зеленодольск муниципаль районы Зур Ключи авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә (http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы рәсми сайты (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче И. И. Шәрифҗанова